СОВЕТ ИШКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Ишкеево,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422161

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИШКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Ишки авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы 422161

тел.(факс): (85563) 2-41-19; e-mail: Ishk.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение | Карар

“03” октябрь, 2016 ел | № 1- 13

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22,56 статьясына, Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына ярашлы 23.03.2004 №23-ТРЗ «Җирле референдум турында», «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Башкарма комитетының»референдум үткәрү инициативасы турында " 2016 елның 23 сентябрендәге 9 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишкиавыл җирлеге Советының» референдум үткәрү инициативасы турында " 2016 елның 23 сентябрендәге 1-12 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Советының 2014 елның 02 апрелендә 2-30 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым салу чараларын җыю һәм куллану, тәртибе һәм гражданнарның үзара салым салу турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымнарын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2016 елның 20 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, I һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә

катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2017 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

**1. Торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру:**

урам яктырту объектларын модернизацияләү (торак пункт территориясендә урам яктырту лампаларын агымдагы ремонтлау, сатып алу һәм алыштыру) – Ишки торак пунктында-50,0 мең сум.

**2.Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны оештыру:**

-Васильево торак пунктында скважина бораулау, су белән тәэмин итү өчен тирәнлек насосы сатып алу һәм урнаштыру-25,0 мең сум

«ӘЙЕ» «ЮК»

3.Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Хабеевка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Ишки авыл Советы рәисе, Башлыгы Ф.Г.Хабеев